Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Ташбилге авыл җирлеге Урта Биктимер авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2019 елның 22 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Ташбилге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, 2019 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлегендә халык җыены беркетмәсе нигезендә халык җыены КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге составына керүче Урта Биктимер авылында узган халык җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

**2.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә килешәсезме?:

- урам утларын ремонтлауга, лампаларны, яктырткычларны алыштыруга һәм урам утларын кулланган электр энергиясе өчен түләүгә-100 сум.;

- авыл эчендәге юлларны төзекләндерүгә һәм карап тотуга-300 сум;

- Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү хөрмәтенә үзәк парк өчен коймалар сатып алу һәм урнаштыру, Ташбилге авыл җирлеге һәйкәлләрен һәм обелискларын төзү , ремонтлау өчен - 50 сум.;

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, суэтем башнясы кулланган электр энергиясе һәм суны лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләү-100 сум.;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә, контейнерлар сатып алуга (белгеч эшенә түләү) - 50 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

**3.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларыннан, Бөек Ватан

сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урам утларын ремонтлауга, лампаларны, яктырткычларны алыштыруга һәм урам утларын кулланган электр энергиясе өчен түләүгә-100 сум.;

- авыл эчендәге юлларны төзекләндерүгә һәм карап тотуга-300 сум;

- Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итү хөрмәтенә үзәк парк өчен коймалар сатып алу һәм урнаштыру, Ташбилге авыл җирлеге һәйкәлләрен һәм обелискларын төзү , ремонтлау өчен - 50 сум.;

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, суэтем башнясы кулланган электр энергиясе һәм суны лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләү-100 сум.;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә, контейнерлар сатып алуга (белгеч эшенә түләү) - 50 сум.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Ташбилге авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Ташбилге авыл җирлеге башлыгы: Р. Ф. Әхмәдиев